ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 3 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясындагы 1 өлешенең егерме икенче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2; 2016, № 5), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“урман фонды җирләрендә урманнардан файдалануны, аларны саклауны (шул исәптән янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруны һәм урман янгыннарын сүндерүне, моңа урман янгыннарын локальләштерү һәм туктату максатларында шартлату эшләрен башкару һәм урман янгыннарын сүндерү максатларында явым-төшемнәрне ясалма булдыру чараларын кулу керми), яклауны (урманны яклауны районлаштырудан һәм дәүләт урман патологиясе мониторингыннан гайре), торгызуны (урман орлыкларын районлаштырудан, урман үсемлекләре орлыкларының федераль фондын булдырудан һәм урманнар торгызылуга дәүләт мониторингыннан гайре) оештыру һәм күрсәтелгән җирләрдә урманнарны саклауны, яклауны, торгызуны (шул исәптән урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өчен билгеләнгән урман юлларын булдыруны һәм эксплуатацияләүне) тәэмин итү;”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 19 ноябре
№ 87-ТРЗ